РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ТИМЕРШИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422057, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19а
тел. (84362)2-23-23

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТИМЕРШЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422057, Татарстан Республикасы,
Саба районы, Тимершык авылы,
Пионер урамы, 19а йорт
тел. (84362)2-23-23

e-mail: Timer.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
23.10.2024

КАРАР
№23

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Тимершык авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә мәҗбүри салым түләү билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) 0,1 процент:

- гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан, әлеге пунктның 5 пунктчасында күрсәтелгән;

- һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә корылмаларына карата.

2) 0,2 процент:

– торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

– төзелеп бетмәгән объектларның шул очракта, әгәр мондый объектларның проектлана торган билгеләнеше торак йорт булса ;

- составына бер генә булса да торак йорт кергән бердәм күчемсез комплексларга карата;

3) 0,3 процент фатирларга, фатирларның өлешләренә, бүлмәләргә карата;

4) 2025-2027 еллар чорына 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда – гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата салым салу объектларына карата 2 процент, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган;

5) 2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата;

6) 2,5 процент һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;

7) 0,5 процент башка салым салу объектларына карата.

3. Түбәндәге ташламалар билгеләргә:

3.1. Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатирга милек хокукына ия физик затларга исәпләнгән салым суммасын әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метрының кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага киметү рәвешендә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташлама суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташлама суммасы исәпләнгән салым суммасыннан аны исәпкә алмыйча арта алмый.

3.2. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә - 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарның балаларын.

Салым ташламасы салым салу объектларының чикләнмәгән санына карата бирелә.

Салым ташламасы салым салуның теләсә нинди төр объектларына карата бирелә.

Салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына үз теләкләре буенча салым ташламасы бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документлар бирергә хокуклы.

4. Үз көчен югалткан дип танырга:

Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 14.11.2014 елның 28 номерлы карары;

Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең 07.08.2015 елның «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 14.11.2014 елның 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 24 номерлы карары;

Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең 08.10.2015 елгы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 14.11.2014 елгы 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 10 номерлы карары;

Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең 03.08.2018 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 14.11.2014 елның 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 16 номерлы карары;

Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең 21.11.2018 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 14.11.2014 елның 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 32 номерлы карары;

Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең 25.03.2019 «Татарстан

Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 14.11.2014 елның 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 11 номерлы карары;

Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең 26.11.2019 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 14.11.2014 елның 28 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» 32 номерлы карары;

Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең 16.02.2024 «Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 14.11.2014 елның 28 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» 5 номерлы карары.

5. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма халыкка игълан ителгән көннән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/timershik адресы буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Тимершык авыл
җирлеге Башлыгы | А.Х. Хаҗиев